***Аннотация к рабочей программе***
***Родной язык и литературное чтение на родном языке. 2-9 классы***

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле күләмле укучылар өчен мәктәптә татар теле өйрәнүнең төп максаты- телне аралашу чарасы буларак үзләштерү. Коррекция мәктәпләрендә укучы балаларны тормышка социаль яраклаштыруга юнәлтү максатыннан , татар телен өйрәтү түбәндәге бурычларны үз эченә ала:
-укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләре формалаштыру;
-төрле жанрдагы текстларны аңлап укуга юнәлеш бирү;
-диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре формалаштыру;
-дөрес язу күнекмәләре булдыру;
-татар дөньясына караган мили традицияләр, гореф-гадәтләр, ризыклар, бәйрәмнәр, уеннар, халык авыз иҗаты үрнәкләре белән таныштыру;
-татар әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте турында билгеле бер мәгълүмат җиткерү.
Коммуникатив методикага нигезләнеп татар теленә өйрәтү гомумдидактик принципларга (фәннилек, аңлылык, аңлаешлылык, системалылык, эзлеклелек, күрсәтмәлелек, белемне ныклы үзләштерү); психологик принципларга (мотивация булдыру, укучыларның индивидуаль-психофизик үзенчәлекләрен исәпкә алу); методик принципларга(коммуникативлылык, комплекслылык, укытуны телдән алып бару, сөйләм эшчәнлегенең төрләре арасында тыгыз бәйләнеш булдыру) һәм лингвистик принципларга(телгә өйрәнүне гамәли эшчәнлеккә юнәлтү); тел һәм сөйләм күренешләрен сайлап алу һәм өйрәтүгә функциональ якын килү, тел күренешләрен ситуатив-тематик нигездә өйрәтүгә таянып оештырыла.
Коррекцияләү мәктәпләрендә укучы рус телле балаларның программада күрсәтелгән эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла.
*Диалогик-монологик сөйләм*
Үзенең яшьтәшләре, өлкәннәр белән билгеле бер аралашу сфераларында, ситуацияләрдә диалогик-монологик сөйләм оештыру;
бутап бирелгән сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрне эчтәлек тәртибендә урнаштырып, кечкенә хикәяләр төзү;
укытучы тәкъдим иткән план буенча, терәк сүзләр ярдәмендә укылган хикәянең кыскача эчтәлеген сөйләү.
*Аудирование (тыңлап аңлау)*
Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;
әңгәмәдәшеңнең таныш материалга нигезләнгән сөйләмен аңлау;
зур булмаган аутентик, яки адаптацияләнгән текстларның эчтәлеген тыңлап аңлау
*Уку*
Татар хәрефләрен таный белү, алар белдергән авазларны дөрес әйтү;
әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек, аңлап уку;
укыганның эчтәлеген өлешчә яки тулысынча аңлап бару;
яңа сүзләрнең мәгънәсен сүзлектән таба белү;
укыганда кирәкле информацияне таба белү(эзләнүле уку).

*Язу*
Татар алфавитындагы хәрефләрнең дөрес язылышын истә калдыру:
-хатасыз күчереп яза белү

**Белем һәм күнекмәләргә төп таләпләр.**

**2-3 нче сыйныф**
сүзләрне, җөмләләрне укытучы артыннан дөрес кабатлау;
**4 нче сыйныф**
тыңлаган яки укылган сүзләрдә иҗекләр санын билгели белү;
сүзләрне юлдан –юлга дөрес күчерә белү;
укылган текст буенча гади сорауларга җавап бирә белү;
сюжетлы рәсемнәр буенча җөмләләр төзу.
**5 нче сыйныф**
өйрәнелгән материалга нигезләнгән татарча сөйләмне ишетеп аңлау һәм бирелгән җөмләләр арасыннан эчтәлеккә туры килгәннәрен табып әйтә белү;
тыңлаган яки укылган сүзләрдә иҗекләр санын билгели белү;
сүзләрне юлдан –юлга дөрес күчерә белү;
укылган текст буенча гади сорауларга җавап бирә белү;
басма хәрефләр белән язылган 45-50 сүздән торган текстны дөрес итеп кучереп язу;
сюҗетлы рәсемнәр буенча җөмләләр төзу;
хикәяләү һәм сорау интонацияләрен гамәли үзләштерү.
**6 нчы сыйныф**
Укытучының күрсәтмәләрен бер әйтүдән тулысынча аңлап башкару;
татар теленең барлык авазларын дөрес әйтү күнекмәләрен булдыру;
таныш сүзләрдән торган текстны тыңлап, аның кыскача эчтәлеген русча сөйләп бирү;
сүзлектән файдаланып , таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау;
тексттан эчтәлеген укытучы русча әйткән өзекне табып уку;
ишетеп аңлаган текст буенча әңгәмәдә катнашу;
раслау, инкарь, сорау, боерык җөмлә төрләрен диалогик һәм монологик сөйләмдә куллануны камилләштерү;
өйрәнелгән темалар буенча терәк сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзү.
**7 нче сыйныф**

өйрәнелгән материалга нигезләнгән татарча сөйләмне ишетеп аңлау һәм бирелгән җөмләләр арасыннан эчтәлеккә туры килгәннәрен табып әйтә белү;
калын һәм нечкә сузыклардан торган сүзләрнең әйтелешен гамәли үзләштерү;
җөмләләрне татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү күнекмәләре булдыру;
сүзләрне юлдан – юлга дөрес күчерә белү;
басма хәрефләр белән язылган 40-45 сүздән торган текстны дөрес итеп күчереп язу;
сюжетлы рәсемнәр буенча җөмләләр төзү.

**8 нче сыйныф**

Программага кертелгән һәм өйрәнелгән темага 4 тән дә ким булмаган гади җөмлә кертеп, күрсәтмәлелек һәм терәк сүзләр ярдәмендә, кечкенә хикәя төзеп сөйләү;
Төрле типтагы сорау һәм җавап репликаларын кулланып, көндәлек тормыш белән бәйле ситуацияләргә диалог төзү;
Татар сөйлменә, этикетына караган танышу, исәнләшү, саубуллашу, рәхмәт әйтү, гафу үтенү, котлау сүзләрен урынлы куллана белү;
Укылган яки тыңлаган текстның эчтәлеге буенча, әңгәмәдә катнашып, үз фикереңне әйтә белү;
Русча-татарча, татарча – русча сүзлекләр һәм белешмәләр белән эш итә белү;
Төшереп клдырган хәрефләрне куеп, сүзләрне күчереп язу;
Басма хәрефләр белән язылган 75-80 сүздән торган текстны дөрес итеп күчереп язу.

**9 нчы сыйныф**

Раслау, кабатлау сорау, өстәп әйтү алымнары кулланып, диалоглар төү;
Терәк сүзләрдән файдаланып, рәсемнр буенча 3-4 җөмләдән торган кечкенә хикәя язу;
Басма хәрефләр белән язылган 80-85 сүздән торган текстны дөрес итеп күчереп язу
Укытучының (сыйныфташының) өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау.
Укытучы тәкъдим иткән, программада каралган темалар буенча әңгәмә кору.
Диалогта катнашу.
Текстның эчтәлеген сөйләү. Рәсем яки план нигезендә сөйләү.
Укыганның эчтәлеген сораулар нигезендә сөйләү.
Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкият) сәнгатьле итеп уку.
Кыска сүзләрне тулы килеш, озын сүзләрне иҗекләп уку.
Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.

**Программа материалын өйрәнү өчен тәкъдим ителгән дәреслекләр**

2 нче сыйныф. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 1 нче сыйныф. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 2 нче сыйныф .Икенче кисәк. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән.

3 нче сыйныф. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 2 нче сыйныф.. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 2 нче сыйныф .Икенче кисәк. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән.

4 нче сыйныф. *Юсупов Ф.Ю.,Казыйханова З.А., Мөхиярова Р.Х.,* Татар теле.2 нче сыйныф (рус телендә сөйләшуче балалар өчен). – Казан: Мәгариф,1997.

5 нче сыйныф. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 2 нче сыйныф.Беренче кисәк. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән. *Р.З.Хәйдәрова, Р.Һ.Рангулова*. Татар теле һәм уку китабы. 2 нче сыйныф .Икенче кисәк. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. – 2009.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән.

6 нчы сыйныф. *Р.З.Хайдарова*.Татар теле һәм уку китабы. 3 нче сыйныф өчен дәреслек ( рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2002.

7 нче сыйныф. *Р.З Хәйдарова,* Татар теле һәм уку китабы. 4 нче сыйныф. Ике кисәктә. (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Казан: Мәгариф, 2005г.

8 нче сыйныф. *Хәйдәрова Р.З.,* Татар теле. 5 нче сыйныф.-Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011

9 нчы сыйныф. *Хәйдәрова Р.З.,Нәҗипова З.Р.* Татар теле. 6 нчы сыйныф.-Казан: Мәгариф нәшрияты, 2007.